**IV ЧАКЫРЫЛЫШ ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МӨСЛИМ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ СОВЕТЫНЫҢ II СЕССИЯСЕ**

**К А Р А Р № 14**

Мөслим «13» ноябрь 2020 ел

**«Татарстан Республикасы Мөслим муниципаль районы милкендәге җир кишәрлекләре белән яңадан бүлешү нәтиҗәсендә хосусый милектәге җир кишәрлекләре мәйданын арттыру өчен түләү күләмен билгеләү Тәртибен раслау турында» Татарстан Республикасы Мөслим муниципаль районы Советының 2016 елның 11 апрелендәге 33 номерлы карарына үзгәрешләр кертү хакында**

Россия Федерациясе Җир кодексының 39.28 статьясындагы 5 пункты нигезендә, Татарстан Республикасы Мөслим муниципаль районы Советы **КАРАР БИРДЕ:**

1. «Татарстан Республикасы Мөслим муниципаль районы милкендәге җир кишәрлекләре белән яңадан бүлешү нәтиҗәсендә хосусый милектәге җир кишәрлекләре мәйданын арттыру өчен түләү күләмен билгеләү Тәртибен раслау турында» Татарстан Республикасы Мөслим муниципаль районы Советының 2016 елның 11 апрелендәге 33 номерлы карарына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

Татарстан Республикасы Мөслим муниципаль районы милкендәге җир кишәрлекләре белән яңадан бүлешү нәтиҗәсендә хосусый милектәге җир кишәрлекләре мәйданын арттыру өчен түләү күләмен билгеләү тәртибенең 3 пунктын түбәндәгечә бирергә:

«Түләү күләме формула буенча исәпләнә дип билгеләргә (әлеге Тәртипнең 4 пунктында каралган очрактан тыш):

$$Рп = (П2 - П1) \times УПКСчс,$$

биредә:

Рп – түләү күләме;

П2 − хосусый милектәге җир кишәрлеген яңадан бүлү турындагы килешү нигезендә төзелгән җир кишәрлеге мәйданы;

П1 − шәхси милектә булган элеккеге җир кишәрлегенең яңадан бүлү турында килешү төзелгәнче мәйданы;

УПКСчс - хосусый милектә булган, мәйданы яңадан бүлү нәтиҗәсендә арта торган җир кишәрлеге өчен кадастр бәясенең чагыштырма күрсәткече. УПКСчс җир кишәрлегенең кадастр бәясен аның мәйданына (сум/кв.м) бүлү юлы белән билгеләнә».

2. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Татарстан Республикасы Мөслим муниципаль районының Мөлкәт һәм җир мөнәсәбәтләре палатасы рәисенә йөкләргә.

Мөслим муниципаль районы Башлыгы,
Мөслим муниципаль районы Советы рәисе Р.Х. Муллин